| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>КУШМАНСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>КАЙБИЦКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН<br>РЕСПУБЛИКАСЫ<br>КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ<br>КОШМАН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

08.05.2024 ел Кошман ав. № 78

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының «Кошман авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә хуҗасыз күчемсез һәм вариссыз калган мөлкәтне ачыклау, исәпкә алу һәм муниципаль милеккә рәсмиләштерү тәртибен раслау турында

Россия Федерациясе Гражданлык кодексы нигезләмәләре, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Күчемсез милекне дәүләт теркәве турында» 2015 елның 13 июлендәге 218-ФЗ номерлы федераль законнар нигезендә, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының «Кошман авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, «Хуҗасыз күчемсез әйберләрне исәпкә алу тәртибен билгеләү турында» 2023 елның 15 мартындагы П/0086 номерлы Росреестр боерыгы белән, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Кошман авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының «Кошман авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә хуҗасыз күчемсез һәм вариссыз калган милекне ачыклау, исәпкә алу һәм муниципаль милеккә рәсмиләштерү тәртибен (1 нче кушымта) расларга;
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru/) һәм Кошман авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында бастырып чыгарырга һәм «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Кошман авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы
Кошман авыл җирлеге Башлыгы Л.Р. Сафина

Кайбыч муниципаль районы
«Кошман авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге Советының
2024 елның 08.05. 78 номерлы
карарына 1 нче кушымта

# Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының «Кошман авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә хуҗасыз күчемсез һәм вариссыз калган мөлкәтне ачыклау, исәпкә алу һәм муниципаль милеккә рәсмиләштерү ТӘРТИБЕ

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының «Кошман авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә хуҗасыз күчемсез һәм вариссыз калган мөлкәтне ачыклау, исәпкә алу һәм муниципаль милеккә рәсмиләштерү тәртибе (алга таба - Нигезләмә) Россия Федерациясе Граждан кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Күчемсез милекне дәүләт теркәвенә алу турында» 2015 елның 13 июлендәге 218-ФЗ номерлы Федераль закон, «хуҗасыз күчемсез әйберләрне исәпкә алу тәртибен билгеләү турында» 2023 елның 15 мартындагы П/0086 номерлы Росреестр боерыгы нигезендә эшләнде һәм Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы «Кошман авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә (алга таба - Кошман авыл җирлеге) хуҗасыз күчемсез мөлкәтне һәм вариссыз калган милекне исәпкә алу һәм рәсмиләштерү тәртибе, аны муниципаль милеккә исәпкә алу һәм рәсмиләштерү тәртибен билгели.

1.2. Әлеге Тәртип түбәндәгеләргә кагыла:

-Кошман авыл җирлеге территориясендә урнашкан, милекчесе булмаган яисә милекчесе билгеле булмаган, яисә милекчесе баш тарткан күчемсез мөлкәткә;

-Кошман авыл җирлеге территориясендә урнашкан вариссыз калган мөлкәткә.

1.3. Күчемсез милек объектларын хуҗасыз дип тану, күчемсез мөлкәт һәм җир өсте мөлкәте хуҗасыз объектларын исәпкә кую һәм муниципаль милеккә кабул итү өчен документлар рәсмиләштерүне Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының «Кошман авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башкарма комитеты (алга таба - җирлекнең башкарма комитеты) әлеге Тәртип һәм Россия Федерациясе Граждан кодексы, башка норматив хокукый актлар нигезендә гамәлгә ашыра.

1.4. Күчемсез мөлкәтнең хуҗасыз объектларын ачыклау, ачыкланган хуҗасыз күчемсез мөлкәт объектларына муниципаль милек хокукын рәсмиләштерү максатларына һәм бурычларына түбәндәгеләр керә:

-кулланылмаган милекне иреклe гражданлык әйләнешенә җәлеп итү;

- мөлкәтне нормаль һәм куркынычсыз техник эксплуатацияләүне тәэмин итү;

- муниципаль милекне кулланунының нәтиҗәлелеген арттыру;

Кошман авыл җирлеге территориясен төзекләндерү һәм аның тиешле торышы

- «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясында билгеләнгән җирле әһәмияттәге башка мәсьәләләрне хәл итү.

1.5. Әлеге Тәртип белән җайга салынмаган хуҗасыз күчемсез һәм җир өсте мөлкәтен муниципаль милеккә кабул итү мәсьәләләре Россия Федерациясенең гамәлдәге законнары белән җайга салына.

## Кошман авыл җирлеге территориясендә хуҗасыз күчемсез мөлкәтне ачыклау, аны исәпкә алу һәм муниципаль милеккә рәсмиләштерү тәртибе

2.1. Хуҗасыз яисә вариссыз калган билгеләре булган күчемсез мөлкәт турындагы белешмәләр түбәндәгеләрдән керергә мөмкин:

- Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарыннан;

- Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы җирле үзидарә органнарыннан, прокуратурадан;

- инвентаризация үткәрү нәтиҗәсендә;

- Кошман авыл җирлегенең инженерлык инфраструктурасы объектларында ремонт эшләре башкарганда

- юридик һәм физик затларның гаризалары нигезендә;

- башка ысуллар белән.

2.2. Кошман авыл җирлеге территориясендә хуҗасыз күчемсез мөлкәт объектларын ачыклау эшләрен оештыру Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Кошман авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе (алга таба - башкарма комитет җитәкчесе) тарафыннан гамәлгә ашырыла.

2.3. Ачыкланган хуҗасыз күчемсез милек объектларын исәпкә алу һәм муниципаль милеккә рәсмиләштерү җирлекнең башкарма комитеты тарафыннан башкарыла.

2.4. Күчемсез милекнең хуҗасыз объекты турында мәгълүмат алганнан соң 10 эш көне эчендә җирлек башлыгы яисә җирлек башлыгы вәкаләтле заты, әлеге Тәртипкә 1 нче кушымта нигезендәге форма буенча хуҗасыз күчемсез милекне ачыклау акты төзелеп, объектның урнашкан урынына барып, кергән мәгълүматны тикшерә.

2.5. Хуҗасыз күчемсез милек ачыкланганнан соң, башкарма комитет җитәкчесе 10 эш көне дәвамында хуҗасыз күчемсез милек объектлары турында мәгълүматны төгәлләштерү һәм тулыландыру эшен башкара, күчемсез милек объектының милекчесе яки милекчесе билгесез булуын, яки милекченең аңа милек хокукыннан баш тартуын раслаучы документлар җыюны гамәлгә ашыра.

Күчемсез милек объектының хуҗасы булмавын яки аның хуҗасы билгесез булуын раслаучы документлар булып түбәндәгеләр тора:

Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы җирле үзидарә органнары тарафыннан бирелгән әлеге күчемсез милек объекты федераль милек, Россия Федерациясе субъекты милке һәм муниципаль милек реестрларында исәпкә алынмавы турындагы документлар;

-хокуклар БТИ органнарында теркәлмәгән;

-күчемсез милеккә хокукларны теркәүне гамәлгә ашыручы тиешле дәүләт органнары (оешмалары) тарафыннан бирелгән, әлеге күчемсез милек объектларына хокуклар аларның тарафыннан теркәлмәгәнлеген раслаучы документлар;

-күчемсез милеккә хокукларның бердәм дәүләт реестрыннан һәм аның белән күчемсез милек объекты турында килешүләрдән алынган мәгълүмат.

2.5. Милекченең күчемсез милеккә хокукларыннан баш тартуын раслаучы документ булып нотариаль рәвештә расланган милекчедән күчемсез милек объектына милек хокукыннан баш тарту һәм бу милекне хуҗасыз сыйфатында исәпкә куюга ризалык турында гариза тора (милекче бу милеккә милек хокукыннан баш тарткан очракта бирелә).

Милекче - юридик зат милеккә милек хокукыннан баш тарткан очракта һәм, әгәр милек хокукы теркәлмәгән булса, башкарма комитет җитәкчесе соратып ала, йә ведомствоара хезмәттәшлек ярдәмендә түбәндәге документларны ала:

-милек хокукыннан баш тарткан кешенең милек хокукы булуын раслаучы хокук билгеләүче документларның күчермәләре;

-юридик затның оештыру документлары күчермәләре, юридик затның дәүләт теркәве турында таныклык, салым түләүченең идентификацион номеры.

Милекче - физик зат милек хокукыннан баш тарткан очракта һәм, милек хокукы теркәлмәгән очракта, җирлек башкарма комитеты ведомствоара хезмәттәшлек юлы белән түбәндәге документларны ала:

-милек хокукыннан баш тарткан кешенең милек хокукы булуын раслаучы хокук билгеләүче документларның күчермәләре;

түбәндәгеләрне сората:

- юридик зат булдырмаган эшмәкәр буларак физик затны теркәү турында мәгълүмат;

-гражданның шәхесен раслаучы документның күчермәсе.

2.6. Күчемсез милек объекты милекчесе турында мәгълүмат алынган очракта, тиешле объектны исәпкә кую өчен документлар җыю эше хуҗасыз яисә ялган милек буларак туктатыла, бу хакта хуҗасыз күчемсез мөлкәт турында белешмәләр биргән затка хәбәр ителә.

2.7. Күчемсез мөлкәтнең хуҗасыз объекты турындагы мәгълүматларны тикшерү чаралары тәмамланганнан соң 10 эш көне дәвамында, әлеге Тәртипнең 2.6 пунктында күрсәтелгән очрактан тыш, җирлек башкарма комитетының Кошман авыл җирлеге территориясендә урнашкан күчемсез мөлкәтнең хуҗасыз объектларын хуҗасыз дип тану һәм аны Хуҗасыз милек объектлары реестрына (алга таба - Реестр) кертү турында карары чыгарыла.

2.8. Реестрны алып бару җирлек Башкарма комитеты тарафыннан әлеге Тәртипкә 2 нче кушымта белән расланган форма буенча башкарыла.

2.9. Күчемсез милек объектын хуҗасыз дип тану турында Карар кабул ителгәннән соң 30 эш көненнән дә соңга калмыйча, җирлекнең Башкарма комитеты техник инвентаризация органнарында кадастр, техник паспортлар һәм планнар әзерләргә заказ бирә. Техник инвентаризация үткәрү һәм кадастр һәм техник паспортлар әзерләү буенча эшләр җирле бюджет акчалары хисабына башкарыла.

2.10. Хуҗасызлык билгеләре булган мөлкәтне җимерү (югалту) куркынычын булдырмау, гражданнарның тормышына һәм сәламәтлегенә турыдан-туры куркыныч тудыручы авария хәлләре килеп чыгу һәм аның нәтиҗәләрен бетерү максатларында (тормышны тәэмин итү объектларын, инженерлык инфраструктурасын һәм төзекләндерү объектларын тиешле хәлдә тоту өлешендә)

җирлек Башкарма комитеты бу максатларга бүлеп бирелгән җирле бюджет акчалары хисабына әлеге мөлкәтнең һәм аның чикләренең саклануын тәэмин итә.

Күрсәтелгән хуҗасыз милеккә муниципаль милек хокукы танылганчы ачыкланган хуҗасыз җылылык челтәрләрен тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү «Җылылык белән тәэмин итү турында» 2010 елның 27 июлендәге 190-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә башкарыла.

Күрсәтелгән хуҗасыз милеккә муниципаль милек хокукын таныганчы яисә аларны үзләштергәнче кайнар су белән тәэмин итү, салкын су белән тәэмин итү һәм (яисә) ташландык суларны агызу үзәкләштерелгән системаларының, шул исәптән суүткәргеч һәм канализация челтәрләренең ачыкланган хуҗасыз объектларын тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү, мондый объектларны калдырган милекчегә Россия Федерациясенең гражданлык законнары нигезендә файдалану һәм боерык бирү «Су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу турында» 2011 елның 07 декабрендәге 416-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә гамәлгә ашырыла.

2.11. Ачыкланган күчемсез милек объектын исәпкә кую Росреестрның 2023 елның 15 мартындагы П/0086 номерлы «Хуҗасыз күчемсез милек әйберләрен исәпкә алу тәртибен билгеләү турында» боерыгына ярашлы рәвештә җирлек башкарма комитеты тарафыннан башкарыла.

2.12. Хуҗасыз күчемсез милек объекты исәпкә куелганнан соң бер ел узгач, җирлекнең башкарма комитеты мондый объектка муниципаль милек хокукын тануны таләп итеп, судка мөрәҗәгать итә.

Ачыкланган электр челтәре хуҗалыгы объектларын һәм башка линия объектларын исәпкә кую җирлек башлыгы тарафыннан «Электр энергетикасы турында» 2003 елның 26 мартындагы 35-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә башкарыла.

Линия объектларына карата хуҗасыз күчемсез милек исәпкә куелган көннән алып өч айга кыскартылган срок билгеләнгән, ул тәмамлангач, җирлек башлыгы муниципаль милек хокукын тану таләбе белән судка мөрәҗәгать итә ала.

2.13. Хуҗасыз күчемсез милек объектларын муниципаль милеккә кабул итү әлеге Тәртипнең 2.12 пунктында күрсәтелгән гаризаны карау нәтиҗәләре буенча чыгарылган судның законлы көченә кергән карары нигезендә гамәлгә ашырыла.

2.14. Күчемсез милеккә хокукларны дәүләт теркәвен гамәлгә ашыручы органда муниципаль милек хокукын дәүләт теркәве буенча чаралар муниципаль милек хокукын тану турында суд карары законлы көченә кергәннән соң 10 эш көне эчендә җирлекнең башкарма комитеты тарафыннан гамәлгә ашырыла.

2.15. Муниципаль милек хокукын җирлекнең башкарма комитеты теркәгәннән соң, 10 эш көне дәвамында объектны реестрдан чыгару һәм муниципаль милек реестрына кертү буенча чаралар үткәрелә.

2.16. Муниципаль милек хокукы теркәлгәннән соң Башкарма комитет әлеге күчемсез милек объектлары астындагы җир кишәрлекләрен муниципаль милеккә рәсмиләштерү буенча чаралар үткәрә.

### Кошман авыл җирлеге территориясендә вариссыз калган мөлкәтне ачыклау һәм муниципаль милеккә рәсмиләштерү тәртибе

3.1. Закон буенча муниципаль берәмлеккә мирас хокукы буенча күчүче вариссыз калган мөлкәт дигәндә гражданнарга милек хокукында булган һәм, әгәр дә закон буенча да, васыять буенча да варислар булмаса, яисә варисларның берсе дә мирас итеп калдырырга хокуклы булмаса яки варисларның барысы дә мирастан

читләштерелгән булса, йә варисларның берсе дә мирасны кабул итмәгән булса, яки барлык варислар да мирастан баш тартсалар һәм шул ук вакытта аларның берсе дә башка варис файдасына баш тартуын белдермәсә, шулай ук, әгәр мал-мөлкәт муниципаль берәмлек васыяте буенча тапшырылган булса.

3.2. Закон буенча мирас тәртибендә гамәлдәге законнар нигезендә муниципаль милеккә Кошман авыл җирлеге территориясендә урнашкан түбәндәге вариссыз калган мөлкәт күчә:

- торак бүлмә;

-җир кишәрлеге, шулай ук анда урнашкан биналар, корылмалар, күчемсез мөлкәтнең башка объектлары;

-әлеге пунктның икенче һәм өченче абзацларында күрсәтелгән күчемсез мөлкәт объектларына гомуми өлешле милек хокукындагы өлеш.

3.3. Кошман авыл җирлегенең вариссыз калган мөлкәткә милек хокукын раслаучы документ булып нотариаль орган тарафыннан бирелгән мираска хокук турында таныклык тора.

Вариссыз калган милекне алу өчен мирасны кабул итү таләп ителми.

3.4. Кошман авыл җирлеге территориясендә вариссыз калган милекне муниципаль милеккә рәсмиләштерүне ачыклау эшләрен оештыру җирлек башкарма комитеты тарафыннан гамәлгә ашырыла.

3.5. Вариссыз калган билгеләре булган күчемсез мөлкәт турындагы белешмәләр түбәндәгеләрдән керергә мөмкин:

-Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарыннан;

- Кайбыч муниципаль районының җирле үзидарә органнарыннан;

- инвентаризация үткәрү нәтиҗәсендә;

- идарәче оешмаларның, башка юридик һәм физик затларның гаризалары нигезендә;

-башка ысуллар белән.

3.6. Вариссыз калган мөлкәт турында белешмәләр кергән вакыттан алып 5 көн эчендә җирлек башкарма комитеты түбәндәге документларны бирү турында тиешле органнарга һәм оешмаларга запрослар җибәрә:

- үлем турында ГХАТ учреждениеләре биргән таныклыклар (белешмәләр);

- вафат булган гражданның җир кишәрлегенә, шулай ук анда урнашкан биналар, корылмалар, башка күчемсез мөлкәт объектлары (аларның өлешләре) турында хокук билгели торган һәм (яисә) хокукын раслый торган документлар;

- үлгән гражданның җир кишәрлегенә милек хокукы турында Милеккә хокук бердәм дәүләт реестрына язма кертүне раслаучы (алга таба - Реестр) өземтәләр, шулай ук анда урнашкан биналар, корылмалар, күчемсез мөлкәтнең башка объектлары (аларның өлешләре);

-җир кишәрлегенә кадастр һәм техник паспорт, шулай ук анда урнашкан биналар, корылмалар, күчемсез мөлкәтнең башка объектлары (аларның өлешләре);

-нотариуска ачык нәсел эшләре булу яисә булмау турында сорау.

3.7. 6 бүлекчәдә күрсәтелгән документлар җирлек башкарма комитетына кергәннән соң, әлеге документлар, шулай ук бинаның, корылманың, күчемсез мөлкәтнең башка объектының, күчемсез мөлкәтне техник инвентарьлаштыруны гамәлгә ашыручы оешма тарафыннан бирелгән бәясе, җир кишәрлегенең кадастр хакы турындагы белешмә яисә милекне бәйсез бәяләү турындагы хисап, җир кишәрлеге милекчесе вафат булган көннән алып 6 ай вакыт узганнан соң мираска

хокук турындагы таныклыкны рәсмиләштерү өчен, шулай ук анда урнашкан биналар, корылмалар, күчемсез мөлкәтнең башка объектлары (аларда өлешләр) турында белешмә канун буенча мирас ачу урыны буенча нотариуска җибәрелә.

3.8. Нотариус вариссыз калган милеккә хокук турында таныклык бирүдән баш тарткан очракта, җирлек башкарма комитеты муниципаль милекнең вариссыз калган милкенә хокукын тану турында судка дәгъва белән мөрәҗәгать итә.

3.9. Вариссыз калган милеккә хокук турында таныклык алганда йә вариссыз калган милеккә муниципаль милек хокукын тану турында суд карары үз көченә кергәндә җирлек башкарма комитеты вариссыз калган мөлкәткә муниципаль милекнең хокукларын хокукларны теркәү органнарында дәүләт теркәвенә алуны тәэмин итә.

3.10. Күчемсез милеккә хокукларны дәүләт теркәвенә алганнан соң җирлек башкарма комитеты:

- вариссыз калган мөлкәтне Кошман авыл җирлеге казнасы составына муниципаль милеккә кабул итү һәм кертү турында карар проектын әзерләүне тәэмин итә;

-муниципаль мөлкәт реестрына тиешле белешмәләр кертүне тәэмин итә.

3.11. Кошман авыл җирлеге территориясендә урнашкан, билгеләнгән тәртиптә теркәлгән милек хокукы теркәлгән торак урыннар (шул исәптән торак йортлар һәм аларның өлешләре) рәвешендәге вариссыз калган мөлкәт, социаль файдаланудагы торак фондына кертелә.

Хуҗасыз күчемсез һәм вариссыз калган
мөлкәтне ачыклау, исәпкә алу һәм
муниципаль милеккә рәсмиләштерү
тәртибенә 1нче кушымта

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы
«Кошман авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә хуҗасыз
күчемсез милекне ачыклау АКТы

«__» ________________ ел ____________ ав._

____________________________________________________________тарафыннан

(ФИО һәм вазифа күрсәтелә)

кабул ителгән гариза (мөрәҗәгать) нигезендә __________(керү номеры) хуҗасыз билгеләре булган күчемсез мөлкәт объекты тикшерелде.

Милек исеме ____________________________________________________________

Милек урнашу урыны ____________________________________________________

Милекнең кыскача характеристикасы ______________________________________

Милек хуҗасыз дип саналырга мөмкин булган билгеләр ___________________

Элекке мөлкәт хуҗасы ___________________________________________________

Мөлкәт нинди вакыттан бирле хуҗасыз ____________________________________

Имза:

Хуҗасыз күчемсез мөлкәтне ачыклау, исәпкә алу һәм муниципаль милеккә рәсмиләштерү тәртибенә 2 нче кушымта

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы «Кошман авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә хуҗасыз күчемсез милек объектлары РЕЕСТРЫ

| № т/б | Объект исеме | Объект урнашу урыны | Объектка кыскача характеристика | №, хакимиятнең объектны хуҗасыз дип тану турындагы карары датасы | Теркәү органында исәпкә кую датасы | Искәрмә |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |